# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Монашево торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15.11.2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 120 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары белән 2024 елның 15 ноябре 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Монашево авылы гражданнар җыенында "2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлегенең Монашево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы? дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде.

1) Монашево торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;
2) Монашево торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган яктырткычларны һәм урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм алмаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
3) Монашево торак пунктындагы каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүп контейнерлары сатып алу)?»
4) Монашево торак пунктында Елга аръягы һәм Михаил Петров урамнары буенча гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, тигезләү, эшләрне килешү буенча түләү)?»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 221 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 113

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" - 113 граждан тавыш бирде;

"ЮК" - 0

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлегенең Монашево авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. “2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлегенең Монашево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы? дигән сорау каралды һәм карар кабул ителде:

1) Монашево торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;

2) Монашево торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган яктырткычларны һәм урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм алмаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) Монашево торак пунктындагы каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүп контейнерлары сатып алу)?»

4) Монашево торак пунктында Елга аръягы һәм Михаил Петров урамнары буенча гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, тигезләү, эшләрне килешү буенча түләү)?»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә Монашево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Монашево авыл җирлеге” бүлегендә (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Иосифов